| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА ЯКУШКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

Якушкино ав.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» ноябрь 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Якушкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ**:**

1. 2025 елның 21 ноябрендә Нурлат муниципаль районы Якушкино авылы, Гагарин урамы, 2а йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 13 сәгать 00 минутка Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Якушкино авылы гражданнарыннан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары һәм уку йортларында көндезге уку формасы буенча белем алучы студентларның тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х. Хәмидуллин